**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районы**
**Кадер авыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

**№ 96** **«02» март 2023 ел**

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Кадер авыл җирлеге муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 29 декабрендәге 21 нче номерлы Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 05 декабрендәге 512-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Зәй муниципаль районының Кадер авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Кадер авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Кадер авыл җирлеге муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 29 декабрендәге 21 нче номерлы Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлеге Советы карарына (Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлеге Советының 2021 елның 20 апрелендәге 32 нче номерлы, 2022 елның 21 мартындагы 57 нче номерлы, 2022 елның 28 ноябрендәге 80 нче номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.6. Аукционда катнашу өчен дәгъва итүче түбәндәге күләмдә алдан акча (задаток) кертә:

100 миллион сум һәм аннан да күбрәк сумманы тәшкил иткән муниципаль мөлкәтне сату турында мәгълүмати хәбәрдә күрсәтелгән башлангыч бәянең 20 процентын;

100 миллион сумнан кимрәк тәшкил иткән муниципаль мөлкәтне сату турында мәгълүмати хәбәрдә күрсәтелгән башлангыч бәянең 10 процентын.»;

1.2. Түбәндәге эчтәлекле 5.6.1 пунктын өстәргә:

«5.6.1. Мәгълүмати хәбәрдә күрсәтелгән счетка алдан акча (задаток) кертүне раслый торган документ булып шушы счеттан өземтә тора.»;

1.3. 6.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.3. Аукционда катнашу өчен дәгъва итүче түбәндәге күләмдә алдан акча (задаток) кертә:

100 миллион сум һәм аннан да күбрәк сумманы тәшкил иткән муниципаль мөлкәтне сату турында мәгълүмати хәбәрдә күрсәтелгән башлангыч бәянең 20 процентын;

100 миллион сумнан кимрәк тәшкил иткән муниципаль мөлкәтне сату турында мәгълүмати хәбәрдә күрсәтелгән башлангыч бәянең 10 процентын.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU), җирлек торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

3. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Совет рәисе,**
**авыл җирлеге башлыгы** **Л.Н. Барсукова**